ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

# Сәвәләй мәдәни яңарыш кичерә




Сәвәләй - эшчән, тырыш халкы, күренекле якташлары белән данлыклы җирлек. Алдагы елларда бирегә табиб амбулаториясе, узган ел исә спорт мәйданчыгы, төзекләндерүдән соң фермалар ачылса, быел исә "Авылларда мәдәни объектларны капиталь төзекләндерү" программасы кысаларында мәдәният йорты ремонт эшләреннән соң зур яңарыш кичереп ачылды. Алдагы дүрт-биш елда исә "Авыл клублары төзү" программасы кысаларында Бохарай, Югары Пәнәче, Сармашбаш, Иске Тәкмәк, Түбән Лоҗы, Поповка авыллары заманча клублы булып, халыкка мәдәни хезмәт күрсәтүдә гөрләп эшләп китте. Алар сафына Сәвәләй мәдәният йорты да өстәлде.

Мәдәният йортында төзекләндерү эшләре агымдагы елның март аенда башланган иде. Клубны төзекләндерүгә республика һәм район бюджетларыннан 8әр миллион сум акча бүленде, эшне "Зәй төзелеш компаниясе" җаваплылыгы чикләнгән ширкәте сыйфатлы итеп, вакытында тапшырды. Бирегә элекке бинаның бөтен җылыту системасы, ишек-тәрәзәләр, идән-түшәмнәр алыштырылды, клубның эчке өлеше, фасады яңартылды, янәшә-тирәсе төзекләндерелде, ул яңа җиһазлар белән тулыланды.

-Җирлек халкы элекке мәдәният йортында узган чараларда теләп катнаша, клубка яратып йөри иде, шуңа да алар аның яңарыш кичерүенә чиксез шат,- ди җирлек башлыгы Валерий Маркелов.

Сәвәләйлеләр мәдәни учакның төзекләнүен түземсезләнеп көтте. Аны ачу тантанасына Иске һәм Яңа Маврин, Чыбыклы, Якты Күл авыллары халкы да килгән иде. Сәвәләйлеләрнең сөенеченең чиге булмады, халыкның тантанага күпләп килүе - аның никадәр кирәк булуына ишарә. Сәвәләйлеләрнең шатлыгын уртаклашырга район башлыгы Разиф Кәримов, аның урынбасары Валерий Акатьев, башкарма комитет җитәкчесе Илнар Хафизов, подрядчы оешма вәкилләре дә килгән иде. Район башлыгы республикадагы программаларга, аеруча "Авыл клублары" һәм "Авылларда мәдәни объектларны капиталь төзекләндерү" программаларына кирәк тукталып, халыкны мәдәни-агарту юнәлешендә зур эш башкарылуын, аның буенча районда эшнең дәвам итүен ассызыклады. Бу программалар өчен ТР Президенты Рөстәм Миңнехановка рәхмәт сүзләрен җиткерде, мәдәният хезмәткәрләрен яңып эшләргә чакырды.

-Шәһәрдә яшәүчеләр белән бер хокукта сез. Ял һәм эш өчен мөмкинлекләр бар. Сәвәләйлеләр - тырыш халык, бу турыда "Зәй шикәре" агрофирмасы "Сәвәләй" бүлекчәсенең уңай эш нәтиҗәләре сөйли. Мәктәбегезнең түбәсен яңартабыз, алга таба бирегә төзекләндерү эшләре дәвам итәчәк, - диде Разиф Кәримов.

Аннан район башлыгы мәдәният йорты каршына подрядчы оешма вәкилләрен дәшеп, аларга эшне сыйфатлы итеп, үз вакытында тапшырганнары өчен район башлыгы Мактау грамоталары тапшырды.

Элекке мәдәният йорты моннан ярты гасыр элек файдалануга тапшырылып, ул шактый



тузган, искергән, таушалган иде. Сәвәләйлеләр мәдәният йортын төзекләндерү турындагы хәбәрне шатланып кабул итте. Алар ремонт барышын да көз уңында тотты. Яңарган мәдәни учак хәзер авылга ямь өстәп тора.

- Мәдәният учагын үзебез дә танымыйбыз. Шундый заманча, купшы клубларда эшләрбез дип хыялланмаган идек. Хәзер коллективыбыз белән тагын да тырышып эшләрбез дип ниятләп торабыз, - ди мәдәният йорты директоры Ольга Бутяева.

Әлеге бинада китапханә һәм авыл җирлеге дә урнашкан. Җирлеккә бинаның икенче ягыннан керәсе. Шунысы игътибарга лаек, авыл уртасында ике социаль объект янәшә, алар – табиб амбулаториясе һәм заманча клуб. Әлеге объектларны авылның йөрәге, дисәң дә була.

- Клубны төзекләндерү барышын күзәтеп бардык, мәдәният хезмәткәре Ольга Бутяеваның матур эш-гамәлләрен хуплыйбыз, яңа мәдәният учагында бергәләп тагын да мавыктыргыч чаралар оештырырбыз, - ди Мария Черкасова.

Мария үзе дә үзешчән сәнгатьтә актив катнаша икән, шулай яңып яшәргә тормыш кызыклы була шул.

Клубның сафка басуына иң нык сөенүче яшьләр булгандыр. Юлия Пляшеваның шатлыгы йөзенә үк чыккан, моңа кадәр күрше авылларда көнләшеп яши идек, без - Сәвәләй егет-кызлары да заманча клублы булдык, ди ул, куанып.

Урта, өлкән буын исә элекке клубның ачылуын әле дә хәтерли.

- Авылда мәдәният йорты ачылуны әле дә хәтерлим, ул вакытта миңа 13 яшь иде. Ул кичтә мәдәният сараенда зур тантана - бәйрәм булды. Яңа бинаны күрергә яше-карты килде. Агач чиркәүне яраклаштырып эшләнгән клубтан соң, мәдәният йорты безнең өчен әйтеп бетермәслек биниһая матур, зур, якты бина иде. Буяу исе дә бетмәгән ике йөз урынга исәпләнгән тамаша залында утырып, беренче мәртәбә киң экранда төсле музыкаль француз фильмы карадык. Мин музыкага хирыс яшүсмерне әлеге фильм нык тәэсирләндерде. Нәкъ менә шул клуб сәхнәсендә җырлый башладым. Шушы сәхнә мине олы иҗат юлына чыгарды дип саныйм,-ди хезмәттәшебез, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Николай Шамионов.

Әлеге мәдәният йортында куелган фильмнарны, Камал театры артистлары сәхнәләштергән спектакльләр, башкала җырчылары башкаруындагы җырларны матур бер хатирә итеп искә ала Сәвәләйнең өлкән һәм урта буыны.

Якташыбыз Виталий Агапов иҗаты да шушы клуб белән бәйле. "Сәвәләй"керәшен фольклор ансамбле бирегә аның җитәкчелегендә оеша һәм бүгенге көндә дә мәгълүм коллектив булып кала бирә. Аның тарафыннан иҗат ителгән "Сәвәләй" җыры - авылның гына түгел, районның визит карточкасы.

Яңартылган мәдәният йорты ачылган көнне аның сәхнәсендә балалар хореографик һәм вокаль коллективлары чыгыш ясады. Килгән кунаклар һәм сәвәләйлеләрне җырчы, композитор, Татарстанның халык артисты Виталий Агапов шаян һәм моңлы җырлары белән кинәндерде генә. Ул туган авылында шундый заманча мәдәни учак булуына шатлыгын яшермәде.

Әлеге клуб озак еллар шулай халыкка хезмәт итсен, аның сәхнәсеннән авыл һәм район үзешчәннәре, башкала артистлары әзелмәсен. Бирегә яңа талантлар ачылсын, артистлар үсеп чыксын.

***Разимә КАШАПОВА.***
*Автор фотосы.*

"01" ХЕЗМӘТЕ КИСӘТӘ

# Бакча чүбе яндыру куркыныч тудыра

Көзге-кышкы чорга кердек. Күпләребез бу чорда янгыннар чыгу мөмкинлеге азайды дип уйлый. Әмма бу - ялгыш фикер, әле янгыннар чыгу куркынычы саклана. Нәкъ шушы чорда, бакчаларда уңышны җыеп алгач, калган чүп-чарны яндыру актив төс ала. Югыйсә августта гына күп регионнарда, шул исәптән Волгоград өлкәсендә корган үлән янып китүдән чыккан коточкыч масштабтагы янгын күпме кешене йортсыз-җирсез калдырды. Янгыннар чыгуның төп сәбәбе дә – ут белән сак эш итмәү, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәмәү.

Янгын күзәтчелеге хезмәте зәйлеләрдән бакчаларда җыелган чүпне яндырудан тыелып торуны сорый. Закон нигезендә торак пунктларының гомумкуллану биләмәләрендә чүп-чар яндыру, учак ягу тыела. Бакчада калдыкларны яндырырга уйлаган очракта да, моны янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозмыйча эшләргә кирәк: 5 метр радиустагы биләмәне тиз янучан материаллардан чистартырга, чүпне тимер мичкәгә тутырып ягарга (аны тиз генә каплау өчен янәшәдә тиешле зурлыктагы калай булу яхшы), учак бина-каралтылардан тиешле ераклыкта булырга тиеш, запаста су һәм янгын сүндерү җиһазлары булу зарур. Чүп-чарны мичтә яндыру – иң кулай вариант. Бу очракта да янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре төгәл үтәлергә тиеш. Җилле көнне чүп яндыру бөтенләй рөхсәт ителми. Учакны караучысыз калдырырга да ярамый.

Ут кулланганда тиз янучы сыекчалар, шартлый торган материаллар куллану тыела.Чөнки алар янган вакытта токсинлы һәм югары токсинлы матдәләр бүлеп чыгара. Учак янып беткәч, аны туфрак белән күмәргә яисә яхшылап су сибәргә кирәк. Шушы гади генә таләпләрне үтәгән очракта, ут сезнең милкегезгә бәла-каза салмас.

Янгын сүндерүчеләрне чакыру өчен телефоннар: 01, 7-40-01, кәрәзле телефоннан – 101.

